**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

13.03.2023 № 256-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 28 февралендәге 155-п номерлы боерыгы белән расланган Төбәк дәүләт экология контроле кысаларында Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан кулланыла торган тикшерү кәгазе (аларга булган җаваплар контрольлектәге зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында раслый торган тикшерү сораулары исемлеге) формасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Төбәк дәүләт экология контроле кысаларында Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан кулланыла торган тикшерү кәгазе (аларга булган җаваплар контрольлектәге зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында раслый торган тикшерү сораулары исемлеге) формасын раслау турында» 2022 елның 28 февралендәге 155-п номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 26 июлендәге 630-п номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Төбәк дәүләт экология контроле кысаларында Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан кулланыла торган тикшерү кәгазе (аларга булган җаваплар контрольлектәге зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында раслый торган тикшерү сораулары исемлеге) формасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

14 пунктта:

«Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган сораулар» дигән икенче графаның 5 нчы соравын түбәндәге редакциядә бирергә:

«5. Калдыклар белән эш итү өлкәсендә эшчәнлек алып баручы зат барлыкка килгән, эшкәртелгән, утильләштерелгән, зарарсызланган, башка затларга тапшырылган яки башка затлардан алынган, шулай ук урнаштырылган калдыкларны исәпкә алып барамы?».

2. Хокукый тәэмин итү бүлеге әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары в.б. И.И.Гойбәдуллинга йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков